СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423181, РТ, Новошешминский район, село Тубылгы Тау, ул.Молодежная, д.73,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423181,ТР, Яңа Чишмә районы, Тубылгы Тау авылы, Яшьләр урамы, 73

тел.:(8-84348)3-82-58,факс:(8-84348)3-82-44,Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның 31 нче мае № 20-69

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 июнендәге 28-68 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгытау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү кагыйдәләре»нә үзгәрешләр кертү**

«Ветеринария турында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының 2017 елның 27 июнендәге 28-68 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Тубылгытау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең төзекләндерү кагыйдәләре»нә киләсе үзгәрешләр кертергә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советы карарлары редакциясендә: 17.01.2018 №36-87; 25.05.2018 № 41-98; 27.06.2019 №54-128; 29.04.2021 №10-28):

III бүлекнең 1 пунктындагы 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) терлекчелек продуктлары авыруларын кисәтүне һәм ветеринария-санитария мөнәсәбәтендә куркынычсызлыкны тәэмин итә торган хуҗалык һәм ветеринария чараларын гамәлгә ашырырга, терлекчелек биналарын һәм терлек азыгын саклау һәм терлекчелек продуктларын эшкәртү корылмаларын тиешле хәлдә тотарга, әйләнә-тирә мохитнең терлекчелек калдыклары белән пычрануына юл куймаска;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгытау авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак - коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф. Исмагилов